**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКТАНЫШБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423740, Актаныш авылы, Лесная ур., 2 йорт

**СОВЕТ АКТАНЫШБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423740, село Актаныш, ул. Лесная, дом 2

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

10 ноябрь 2022 ел № 14

Татарстан Республикасы Актанышбаш авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы турында нигезләмәгә һәм гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм файдалану тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияләүне игълан итү турында» Россия Федерациясе Президентының 21.09.2022 № 647 Указына, Актанышбаш авыл җирлеге Уставына таянып Актаныш муниципаль районы Советы, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актанышбаш авыл җирлеге Советы

карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актанышбаш авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм куллану тәртибенә Актаныш муниципаль районы Актанышбаш авыл җирлеге Советы тарафыннан 2014 елның 24 мартында расланган түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 5.1 пунктына түбәндәге редакциядә абзац өстәргә:

"Үзара салым акчаларын түләүдән азат итәргә:

- Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация кысаларында мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары;

- Украинада махсус хәрби операция зонасында контракт буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләр.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында адресы буенча http://aktanysh.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Совет Рәисе Х.М.Хакимов